ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 18 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктында “һәм гражданнарга аның һәркем өчен мөмкин булуын” сүзләрен “, аның сыйфатын һәм һәркем файдаланырлык булуын” сүзләренә алмаштырырга;

2) 27 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:
“3. Әлеге Законның 28 статьясындагы 2 өлешенең 8 пунктында һәм дару чаралары әйләнеше турындагы законнарда каралган дәүләт контролен гамәлгә ашырганда дәүләт контроле органы тарафыннан “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә контроль сатып-алулар башкарыла.”;

3) 28 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Медицина эшчәнлеге сыйфатына һәм иминлегенә дәүләт контроле түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, бюджеттан тыш дәүләт фондларының, медицина оешмаларының һәм фармацевтика оешмаларының сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын үтәүләренә тикшерүләр уздыру;

2) эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә медицина эшчәнлеген лицензияләү;

3) медицина оешмаларының медицина ярдәме күрсәтү тәртипләрен һәм медицина ярдәме стандартларын куллануларына тикшерүләр уздыру;

4) медицина оешмаларының медицина экспертизалары, диспансеризация, медицина тикшерүләре һәм медицина таныклаулары уздыру тәртипләрен үтәүләренә тикшерүләр уздыру;

5) медицина оешмаларының медицина әйберләрен имин куллану һәм эксплуатацияләү, аларны утильләштерү (юк итү) таләпләрен үтәүләренә тикшерүләр уздыру;

6) медицина оешмаларындагы медицина хезмәткәрләренең, җитәкчеләрнең, даруханә оешмаларындагы фармацевтика хезмәткәрләренең һәм җитәкчеләрнең үз һөнәри эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда Федераль закон нигезендә аларга карата кулланыла торган чикләүләрне үтәүләренә тикшерүләр уздыру;

7) Федераль законның 89 статьясындагы 1 өлешендә һәм 90 статьясында күрсәтелгән органнарның һәм оешмаларның медицина эшчәнлеге сыйфатына һәм иминлегенә ведомство контролен һәм эчке контрольне оештыруларына һәм гамәлгә ашыруларына тикшерүләр уздыру;

8) медицина оешмасының түләүле медицина хезмәтләре күрсәтү тәртибен һәм шартларын үтәүләрен тикшерү максатларында контроль сатып-алулар уздыру.”;

4) 30 статьяда “әлеге органнарның, оешмаларның җитәкчеләре тарафыннан билгеләнгән тәртиптә” сүзләрен “аны оештыруга һәм уздыруга карата вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган таләпләргә нигезләнеп” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 05 апрель
№ 29-ТРЗ